

чаян

ISSN 0136-7110

САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ * СЕНТЯБРЬ * 2017 * КАЗАН

9





АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

• Америка, үзенең үлчәм һәм алым системасы ярдәмендә безгә чираттагы икътисадый басымын ясарга әзерләнә.

• Киев, Пхеньян Көнбатышны Украинага карата Рәсәй агрессиясеннән читләштермәсен дигән теләктә, Төньяк Кореяга кисәтү белдергән.

• Узган ел Рәсәйдә иң уңышлы җитештерү итеп миллиардерлар җитештерү танылган.

• УФСИН Серебренниковны лагерь үзешчәннәре арасында танылырга мөмкинлеген әйтте. Аның стилендәге спектакльләр зонада аеруча зур уңыш казаначак икән.

• Мәгариф риформалары Рәсәйдә таптанып тора.

• Кесә телефоны операторлары ФАСка (монополиягә каршы федераль хезмәт агентлыгы) үзләренең роумингын тактылар.

• Үзәк банк, хезмәт хаклары күтәрелүне Рәсәй икътисады өчен иң зур куркыныч нәрсә дип белдерде.

• Украина Ленинны тулысынча җиңүе турында игълан итте.

• Суд, табиб-косметологны уңышсыз операциясеннән соң, үзенең пациентына өйләнергә мәҗбүр итте.

• Төньяк Боз океанында көймәдә Ливиядән җыелган мигрантларны таптылар.

• Ватаныбызның медицина уңышы: паралич суккан авыру хатыннарның күңелен күрә башлаган.

• Тикшерү комитеты, Пенсия фондына иң нык зыян салучылар дип, пенсионерларның үзләрен гаепләгән.

• Йоклап китү өчен, Эльвира Нәбиуллина төннәр буе әле ябылып бетмәгән региональ банкларны саный икән.

• Рәсәй мәгариф министрлыгының тырышлыгына карамастан, РФ җыелма командасы, физикадан Халыкара олимпиадада катнашып, 5 алтын медаль яулап алып кайтты.


• "Пока все дома" тапшыруы, өйдә утыручы геройларның көннән-көн азая баруы сәбәпле, ябылачак икән.

• Тикшерүләр нәтиҗәсендә, гаилә бюджетына иң зур зыян салучы кризис түгел, ә мәктәпкә әзерләнү икәнлеге расланган.

• Сбербанк түләү системасында чуалыш барлыкка килгән. Шул сәбәпле, "Форбс" урыс исемлегендә тагын ике миллиардер өстәлгән.

• Росгвардия сафында профессорларның һәм академикларның митингын куып тарату өчен фәнни рота барлыкка киләчәк.

Илдус АЗИМОВ





ШОМБАЙ
болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Узган елда безнең кечкенә оешмабыз житди югалтуга дучар булды. Яманаты чыккан «Татфондбанк»та безнең 600 мең сум акчабыз янды. Аларны кайтаруга бернинди өмет юк. Шунысы гаҗәп: күптән түгел ул банк талаучыларына әле без тиеш тә булып калганыбыз ачыкланды. Берничә атна элек конкурс идарәчесе исеменнән хат алдык. Аның сүзләренә караганда, безнең аңа 30 сум 00 тиен бурычыбыз бар икән. Касса-хисап хезмәте комиссиясен түләү өчен. Бу аларның безгә йөзләгән мең сумлык «хезмәт күрсәткәннәре» өчендер инде...

Р. ШӘЙХУЛЛИН

КАЗАН


Укучыбызның хатына хөрмәтле Шомбай ага җавап бирде.

– Күптән түгел пенсиямне 15 сумга арттырдылар әле, – диде аксакалыбыз. **– Ике айдан аларга ярдәм итә алырмын...**



Виктор ФЁДОРОВ

Александр ЛЕВИТИН



БЕР ФИКЕРГӘ — ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Әгәр дә безнең салым акчасын Мәскәүләргә — 50%, Татарстанга 50% итеп бүлсәк, безгә дәүләтчелек дип уфтану да кирәкмәс иде.

Алмаз Хәмзин. Безгә акча бүлеп яты-шу кирәкми, безгә гадел федерализация кирәк.

Р. Н.: Шөкер, советский цензура бетте, ләкин аңа алмашка кәнәфи биләүче акча-лы баш мөхәррирләр катламы барлыкка килде...

А. Х.: Хәзерге заманда барысын да акча хәл итә... Син хаклы!

Р. Н.: Президентлар китә, ил кала һәм дошманнар кала.

А. Х.: Китми интектерәләр шул...

Р. Н.: Хәтта цирк караганда да башка акыллы гына фикерләр килергә мөмкин...

А. Х.: Син бу арада гел цирк кына карап ятасың, ахрысы?..

Р. Н.: Кешеләр, сәнгать әсәренә тиң бу-лырдай тәнен ямьсезләп, нигә икән татуи-ровка ясаталар?

А. Х.: Гәүдәсендә бүтән юньле "әсәре" булмаганга.

Р. Н.: Уен тәмам булгач, шахмат фигура-лары бөтенесе бер тартмада "тигезләшә".

А. Х.: Яшәү тәмамлангач, барыбыз да җир — "тартмада" тигезләшәбез.

Р. Н.: Бәндә азынса, "банда" исәбенә ке-рер.

А. Х.: "Банда" азынса, ил "кесәсенә" ке-рер.

Алмаз ХӘМЗИН

ЯҢАЧА ФИКЕРЛӘШҮ

Депутат булма — эшлә!

Ял иткәндә балык тотсаң — президент булырсың...

Арты кычыткан — Сүриягә барган.

Саклаганны банк талый.

Аерылганны АКШ ашар.

Азатлык — газаплыктан соң...

БДИ — Балаларны Дивана Итүче имтихан.

"Чакырылмаган" татар урыс-тан әйбәтрәк.

Татар, урыслаша-урыслаша, урыс булмаска тырыша.



Валерий ТАРАСЕНКО

Битараф ярдәмчеләр

«Безгә кояш кирәкми – безгә партия нур сибә! Безгә икмәк кирәкми – эш кирәк!» "Көчле кул чабулар һәм овацияләр" заманында чәчәк атучы социализм шигарьләре турында шулай шаярталар иде. Эшсезлекнең нәрсә икәнен дә белмиләр иде, ә ялкау сорыкортларга дәүләт файдасына чәнечкеле тимерчыбык артында тир түгәргә туры килә иде. Ә бүген ат кебек таза ирләргә дә эш табу үтә кыен. Инвалидлар турында инде сөйләп торасы да юк. Аларның алган пенсияләренә яши торган түгел, ә мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр матди хәлләрен бераз яхшырту хакына теләсә нинди эшкә тотынырга әзер. Ләкин эш бирүчеләр моңа әзер түгел. Дәүләтнең инвалидларны көченнән килгәнчә законнар, махсус программалар, квоталар белән яклап чыгуына карамастан, оешмаларда аларны кире борып җибәрү очраклары бик күп.

Дипломлы юрист Анастасия Завьялова – бала чагыннан ук инвалид. Аңа култык таяклары ярдәмендә йөрергә туры килә. Шул таякларына таянып, ул Казан судларының берсенә практика узарга дип килгән. Ләкин закон сакчылары сәламәт кулларын болгап каршы алган аны: мондый практикантлар безгә кирәк түгел дип. Хәтта практика үтү турында кәгазьләрне дә әмәлләп бирергә әзер булганнар: бүтән монда күренмә генә! Ләкин Анастасия бу "бүләк"тән баш тарткан һәм практиканы башкалар белән бергә үткән. Тик белгечлеге буенча барыбер кыз эш таба алмаган. Яшь юристка моның бары тик аның сәламәтлеге турында кайгырту белән аңлатканнар: имеш, аңа судлар буенча йөрү бик кыен булачак.

Ә бит инвалид һәрвакыт култык таяклары йә коляска ярдәмендә генә йөри торган гарип кеше түгел. Аларның яртысында – эшләргә рөхсәт итә торган өченче группа. Аның буенча чикләүләр шулкадәр аз ки, аларның күбесен эш бирүче сизми дә диярлек. Аңа да карамастан, узган ел эчендә генә биш оешма шундый инвалидларны эшкә алудан баш тарткан. Алар арасында – "Городская стоматология" акционерлык җәмгыятенең беренче филиалы һәм "Казан банкы". Стоматологларның һәм банкирларның инвалидлар өчен эш урыннарына квоталар булган, ләкин алар моның турында онытканнар, күрәсең. Начар хәтер өчен аларның җитәкчеләренә кечкенә генә штраф түләргә дә туры килгән.

Инвалидлар турында еш кына "онытучы" предприятие һәм фирмалар аз түгел. Бу исемлеккә «Казанский электромеханический завод» акционерлык җәмгыяте, Алабугадагы «Аутоматив Гласс Альянс Рус», «Татнефть-АЗС Центр" фирмасының Чаллы филиалы һәм башкалар керә. Төшеп калган оешмалар түгел бит инде югыйсә! Мәсәлән, Казан электромеханика заводында инвалидлар эшли алырлык агач эшкәртү, әзер эшләнмәләрне буяу цехлары бар. Заводта файдаланыла торган автоматиканы да аларга тапшырырга була – роботлар сәламәт кешегә дә, инвалидка да бертөсле буйсына бит...

Аларга югары хезмәт хакы һәм биек кәнәфиләр дә кирәк түгел бит. Бары тик сыек пенсияләренә бераз өстәмә генә. Һәм монда кешеләр аз гына акча өчен хәтта эшләргә дә әзер дигән ямансу гыйбарә искә төшә...

Айдар СУБАЕВ



Валерий ТАРАСЕНКО




Михаил ЛАРИЧЕВ

Василий АЛЕКСАНДРОВ



Вячеслав ШИЛОВ





Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

— Ярлылыктан соң нәрсә килә?

— Хәерчелек.

— Ә хәерчелектән соң?

— Яшәүгә өмет бетү — прожиточный минимум.

• • •

— 300 грамм сыр үлчәгез әле.

— 500 сум.

— Нишләп бик кыйбат?

— Бушка бирелә торган сыр тычкан тәбесендә.

— Тәбесе белән төреп бирегез...

• • •

Фемида белән минем тулаем аңлашу: ул бәйне салмый, ә мин аның күзенә эләкмәскә тырышам.

• • •

Иң яхшы ир — космонавт: хезмәт хакы зур, ярты еллап командировкада, кайчан кайтасын бөтен ил белеп тора.

• • •

Хөкүмәт утырышында:

Авыл хуҗалыгы министры (шатланып): "Мөгезле эре терлек саны елдан-ел арта!"

Пенсия фонда башлыгы (күңелсез генә): "Пенсионерлар саны да шулай ук арта..."

• • •

— Балалар, сезгә әйтергә телим: дөнья хәлләренең катлаулы булу сәбәпле, инглиз телен мәктәпләрдә өйрәнүне туктатырга дигән карар кабул ителде...

— У-ра-а-а!

— Һәм кытай телен өйрәнә башлаячакбыз.

• • •

— Сезнеңчә, аңа, серне әйтеп, ышанырга буламы?

— Тулысынча. Дүрт ел элек аның хезмәт хакын арттырдык, ә хатыны шуны әлегә хәтле белми.

• • •

Безнең шәһәр урамнарында "БПФ шаһитлары" дигән яңа секта вәкилләре пәйда булды.

— Исәнмесез, сезнең белән бәйсез пенсия фонды турында сөйләшәсебез килә. Әйтегез әле, сез пенсиягә ышанасызмы?

Михаил ФРОЛОВ



ҮРТӘМЕШ

ХАТЫН-КЫЗ КҮКРӘГЕНӘ МӘДХИЯ

Күкрәгеңә башны куеп йоклыйм,
Сабый чакны искә төшереп.
Таң алдыннан кинәт уянамын,
Яңакларны шунда пешереп

Йомры күкрәкләргә карап ятам,
Иркәлиләр алар күзләрне.
Уй-тойгыны әйтеп бирер өчен
Табып булмый кирәк сүзләрне.

Үсмер чактан алып үлгәнчәгә,
Әй, хатыннар, сезгә гашыйк без!
Шуңа күрә күкрәк җылысыннан
Аерылмыйча бергә яшик без!

Вахит МӘРГӘН
61 яшь


Түшләренә башны куеп йоклыйм,
Ширбәт аен искә төшереп.
Яшелчә кырында ятам кебек,
Җәннәттән дә яхшы төш күреп.

Йомры кавыннарын саклап яшим,
Минеке бит болар, минеке!
Беркем аны миннән тартып алмас –
Приватизацияләнгәнне!

Хәер, бу дөньяда алай диеп
Булмый әле әйтеп бетереп...
Ир-юньсезләр кызыга торгандыр,
"Зозуля"дай кыяр үстереп!..

Шәмгун МӘЛГУНЬ
69 яшь

Вячеслав ШИЛОВ





Илдар НӘФИЕВ

Илдус АЗИМОВ





Валерий ТАРАСЕНКО





ИСЕРТКЕЧ ЛОТЕРЕЯ

Мурманск өлкәсенең Заполярный шәһәрендә хәмер сатучылар үз эшләрен яңача – иҗат очкыны белән башкарырга булганнар. Законсыз рәвештә тәүлек буе аракы-шәраб белән сәүдә итүне алар лотерея дип атаганнар. Тамак чылатырга теләүче шешә бәясенә лотерея билеты сатып ала. Билет, кагыйдә буларак, отышлы булып чыга, ә бүләккә бер шешә аракы бирелә. Тикшерү органнары бу мәсьәләне әлегә хәл итә алмыйлар: шома сәүдәгәрләрнең бөтен документлары да тәртиптә.

ЯҢА ФИЛОСОФИЯ

Саратов дәүләт университеты профессоры, философия фәннәре докторы, дистәләгән монографияләр авторы Вера Афанасьева философия өйрәнергә... магистратурага укырга керә. Укырга беркайчан да соң түгел. Өстәвенә, моны хәзерге вакытта гамәлдә булган «Педагогның профессиональ стандарты» таләп итә. Эш шунда ки: философ Афанасьева – белеме буенча физик, ә закон вузда укытуны тиешле белгечлек буенча магистратура бетергәннәргә генә рөхсәт итә. Өлкән яшьтәге «студентка» ялгыз түгел – Россиядә меңләгән тәҗрибәле педагогларга тиешле дипломнары булмау сәбәпле, эшләрен югалту яный. Һәм алар кичәге студентларында белем алырга мәҗбүр. Менә шундый яңа философия юнәлеше!

ТУФАН ӨЧЕН ТҮЛӘҮ

Кострома өлкәсенең Макарьево районында яшәүчеләр быел өзлексез яуган яңгырлардан зур зыян күргән. Күпләре көткән уңышларыннан колак каккан. Ә менә җирле коммуналь хезмәткәрләр аларны табигать күренешләреннән дә ныграк гаҗәпләндергән: Макарьево кешеләре июньдә бакчаларына су сипкән өчен счёт алганнар. Ачулары чыккан бакчачыларга бу хәлне гамәлдәге тарифлар белән аңлатканнар. Имеш, җәйге вакытта түтәлгә сибеләсе су өчен түләү автоматик рәвештә исәпләнә икән.

БУШЛАЙ РЕСТОРАН

Кытайлы Вонг Ваюпо самолётның беренче классына билет алган. Тик шушы гадәти вакыйгадан ул үзе өчен зур файда ала алган. Беренче класс пассажирлары, кагыйдә буенча, аэропорт ресторанында бушлай ашый алалар икән. Тапкыр Вонг көн саен аэропортка килеп яхшылап ашап, ә аннан соң билетын икенче көнгә күчереп йөри башлаган. Шулай итеп, үткен кытай егете ел буе бушлай тамак туйдырып йөргән. Тик авиакомпания хезмәткәрләре, моны сизеп, аның өчен ресторанга юлны япканнар.

Алиш ГАБДУЛЛИН

Фрейд өйрәтте

Беркөн атаклы психоаналитик Фрейдның популяр лекцияләрен актарып утырдым. Баксаң, гомерем буе мин аның теориясе буенча яшәп ятканмын икән. Әйе, чыннан да, мине балалар бакчасыннан бирле эротик символика җенләндереп йөрде. Хәзергә хәтле хәтеремдә: беренче тәрбиячебезнең көндезге йокыдан соң барыбызны да песиткечкә утыртканы. Җаныкаем Клавдия Петровна, ул бит минем нинди хисләр белән янып, иң соңга калып утырганымны һәм торып киткәнемне аңлый ала идемени? Фрейд барысын да аңлатып бирә. Клавдия Петровна белән, акылдан шашкандай, бергә буласым килгән ләбаса минем. Ул – игътибарын миңа ныграк юнәлткән бердәнбер гүзәл зат.

Үземнең мәктәптәге укытучымны мин күзләрем белән ашый идем. Миңа җиде яшь, ә аңа – егерме җиде. Кияүдә. Ләкин бу хәл минем хисләремә комачау итмәде. "Сара, сары алма ал. Сары алма сулы ул", – дигән сүзләрне укытучыбыз, сулышы капкандай, хискә бирелеп укыганда мин аның үзен әлеге сулы алма итеп күз алдыма китерә идем. Хәзер Фрейдка рәхмәт кенә әйтәм, аңладым, шул рәвешчә миндә аңсыз рәвештә якынлык кылу инстинкты барлыкка килгән икән.

Безнең пионер лагеренда вожатый булып эшләүче беренче курс студенты Вера бар иде. Озын буйлы, чибәр, муенында пионер галстугы. Ул минем ни өчен барабанчы булып язылуымны ахыргача аңлый алмады. Мин үзем дә ни өчен ару-талу белмичә, кирәкме-кирәк түгелме һәрвакыт барабан төеп утыруымны аңлата алмыйм. Рәхмәт Фрейдка! Шул пионер лагеренда аңладым мин ул әйткән либидо сүзенең мәгънәсен. Яшең арта – хатын-кыз белән кызыксынуың көчәя икән.

Комсомол җыелышларын яратмадым дип әйтә алмыйм. Мин аларга бик теләп йөрдем. Бигрәк тә комсомол секретарен әүлия кебек күрә идем. Мин иң беренчеләрдән булып субботникларга чыгам, кызыл тасма бәйләп, төнге шәһәрдә тәртип саклап йөрим, үзешчән сәнгатьтә актив катнашам... Болар барысы да Елена Петрова аркасында. Ә аның күзе һәрвакыт партком секретарендә, гәрчә, ул гаиләле булса да. Фрейд үзенең лекцияләрендә мондый мөнәсәбәтемне сексуаль һәвәслек дип атаган.

Армиядән соң мин заводка, үземнең эшләп киткән слесарь-ремонтниклар бригадасына кайттым. Нина нормировщица булып эшли иде. Мин шуның матурлыгына хозурланып бирелгән норманы арттырып үти башладым, төннәрен китаплар укыйм, ә көндез Нинага төрле рационализаторлык киңәшләре бирәм. Сәгатьләр буе мин аңа су кранын күрсәтеп, суның аннан ничек акканын аңлатам. Австрия докторы Фрейд бу очракта төшкә кергән сексуаль мөнәсәбәтне сурәтләп аңлатыр иде, әмма, Аллага шөкер, Нина үзе бу нәрсәне бик яхшы белән икән. Һәм без уртак фикергә килдек...



АВЫЛЫМ МӘЗӘКЛӘРЕ

Виктор ФЁДОРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



КИБЕТТӘ ОЧРАШУ

(90 нчы еллар темасына саташу)

Беркөн кичен, арып эштән кайткач,
Чыгарыйм, дип, җанны иреккә,
“Сулап керим”, дидем дә хатынга,
Аракыга киттем кибеткә.


...Нәрсә күрәм:
анда Президент –
Шешәләрне тотып карады,
Ашыкмыйча гына әрҗәсенә
Сыра салды, ике аракы...

Чират тора.
Алда – олы кеше,
Җитәкләүче туган илемне.
Туктап калды кинәт кассада ул:
Җитми моның унбиш тиене!
Табигатьтән үзем киң күңелле:
Җиңел чишәм мин бу төенне.
Тиеш кадәр бакыр табып бирәм,
Актарам да кесә-киемне.
Елмаеп куя моңа илбашы –
“Рәхмәт” диеп миңа баш ия.
Горур хисләр били күңелемне:
Менә ул чын демократия!

...Чәчәк атар илем, без теләсәк,
Тырышлыклар китмәс әрәмгә.
Минем кебек әгәр һәрбер кеше
Президентка килсә ярдәмгә!

Ринат АБЗАЛОВ

Вячеслав БИБИШЕВ





Ринат БӘШИРОВ



ИНШАЛАР ҖЫЕНТЫГЫ

Үзенең романында Толстой Наташа Ростованы кыздан хатынга әйләндергән.

Раскольников Рәсәйне кулына балта алырга чакырган.

Маресьев беренче булып култык таягы белән очкан.

Дулкыннар матросны алдыннан да, артыннан да селеккән.

Түбәгә эре калибрлы яңгыр бәрә башлады.

Бородино сугышы күптәннән, үзгәртеп коруга кадәр үк булган.

Полтава янында руслар белән шведлар мөнәсәбәтләрен ачыклаганнар.

Ленин хатынына хыянәт иткән һәм аның янына бөтен илдән илчеләр йөргән.

Маяковский үзен шәхси эш буенча атып үтергән.

Бродскийга Нобель премиясен СССРда эшләмичә яткан өчен биргәннәр.

Тоткыннар арасында Солженицын авторитет булып саналган.

Хрущев үзенең башмагы белән бөтен прогрессив кешелекне куркыткан.

Ельцин эчкән, ә махмырыннан без интегәбез.

(мәктәп иншаларыннан)

Александр АЛЁШИН





Эрнест ДЫШАЕВ

Мәрьям ЗАРИПОВА

МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛӘНҮ

Иртәгә бәләкәчем беренче сыйныфка бара. Әнә ул, караватында җәелеп, гамьсез йөз белән йоклап ята. Ә минем күзгә йокы керми, борәзлексез әйләнгәләп ятам: ул мәктәпкә әзерме соң? Берәр нәрсә онытылмады микән? Баштагы борчулы уйлар һич тынгы бирми...

«Хәзерге таләпләргә туры китереп, тиз укырга өйрәттек, – дип искә төшерәм. – Яза белә. Йөзгә кадәр саный, ала-куша белә... Рәсәй гимнын җырлап күрсәтә! Ике ел түләүле клубка йөрттек – рәсем ясый, пианинода уйный, бии, яттан шигырь сөйли. Өч яшеннән каратэ белән шөгыльләнә – ул-бу була калса, үзен яклый ала... Татар телен өйрәтергә дип авылдан кайнанайны чакыртып алдык... Безнең белән яшиячәк... Бала хакына ун ел берәр ничек түзәрбез... Дәреслекләр, форма, каләм-дәфтәрләр алдык. Партага да акча таптык... Классында ремонт ясаттык... Ата-аналар белән бергәләшеп электрон класс тактасы алдык.. Мәктәпне саклау өчен түләдек. Сыйныф фондына ирекле взнос ясадык. Мәктәпкә спонсор ярдәме күрсәттек... Булачак класс җитәкчесе өчен бүләккә акча җыйдык...»

Булды бугай инде! Беренче сыйныфка барырга була... Тукта, нидер җитми шикелле! Иртәнгә таба гына исемә төште. Чәчәкләр онытылган! Чәчәксез нинди Белем көне булсын ди! Иртүк кибеткә чабарга кирәк – зуррак букет сайларга. Башкаларныкыннан ким булмасын...



Валерий ТАРАСЕНКО

Искәндәр БОРҺАНОВ

Бердәм коллектив

Нәчәлник таштай авыр карашы белән залда утыручыларны күздән кичерде.

– Безгә тагын ришвәтче тотуга разнарядка җибәргәннәр.

– Бер ай элек җибәргәннәр иде бит инде, без отчётын да яздык ич, – дип тавыш бирде өстәлнең икенче башыннан берәү.

– Димәк, илдә ришвәтчеләр белән хәлләр шәптән түгел, – диде нәчәлник.

– Бу юлы кемне корбан итәбез инде? – диде өметсезләнеп калган шул ук тавыш.

– Кемне дә булса сайларга кирәк! Нинди тәкъдимнәр бар? – дип сорады нәчәлник җитди тавыш белән.

– Әйдәгез, без ришвәтчелекне җиңдек, дип язабыз, – дип тәкъдим кертте кабарынкы чәчле буянган ханым.

– Ә сез мең евро бирүчеләр каршында учыгыз үзеннән-үзе ачылып китмәс дип уйлыйсызмы? Сүзегезне үлчәп сөйләгез, – дип бүлде аны нәчәлник.

– Алайса, әйдәгез, жирәбә салабыз, – дип тәкъдим итте урынбасар.

– Алай бит синең дә, минем дә эләгүебез бар – диде нәчәлник. – Ярый, табигатьне саклау буенча урынбасарда тукталыйк, аның өчен күп бирмәсләр, әле ул үзе яшь тә...

– Нәрсә өчен? – Гаүдәле абзыйларның сыртлары артыннан этәч кебек очынып чыкты урынбасар. – Табигатькә еш йөри башладың, – дип урынына куйды аны нәчәлник. – Хатыныңны берүзен калдырасың, ә балаларың юк. Суд барысын да истә тотачак...

– Мин... мин... төзәлермен! – Табигать саклаучы борыны белән мышкылдап куйды.

– Кайгырма! Беренчедән, утырган вакытта зарплатаң сакланып калачак, ә икенчедән, судта бөтенесен үзең сөйләп бирсәң, срогыңны кыскартачаклар. Ә без инде сине ташламабыз...

– Ә нәрсә сөйлим соң мин анда? Мин бит берни дә... – дип мышкылдады урынбасар.

– Читтән килгән эшкуарларга акча өчен тыюлыкта коттедж төзергә рөхсәт биргәнеңне танырсың... Кирәкле кәгазьләрне ясарбыз, – диде нәчәлник катгый тавыш белән.

– Ә суммасы... нинди? – дип сорады табигать сакчысы соңгы хәленнән. – Йөз мең җитәр бәлки, кимрәк бирерләр иде...

– Йөз меңгә бездә урамда белдерү дә асып булмый! Кимендә – миллион!

– Каян алыйм мин аны... – дип пышылдады урынбасар.

– Урман эчендә коттедж салырга каян алдың соң? Ярар... Берәр ничек җыярбыз...

– Ә минем үзем белән бер тиен дә юк, – дип тавыш бирде буянган хатын.

– Кичкә бөтенегез дә табып китерегез, – диде нәчәлник каты кавыш белән. – Соңыннан премия итеп кайтарырбыз. Бердәм, дус коллективыбыз белән озак еллар эшләрбез әле!



МӘЕТ ӨЧЕН – АКЧА

Кострома шәһәрендә берьюлы дүрт полиция хезмәткәренә каршы җинаять эше кузгатылган. Аларны дөнья куйган якташларының адреслары белән сәүдә итүдә гаеплиләр. Законны бозып, алар бу мәгълүматны ритуал агентлыкларына тапшырганнар. Бушлай түгел, әлбәттә – һәр адрес өчен погонлы мошенниклар 500 сум алып барганнар. Шунысы мәгълүм: шул ысул белән аларның берсе генә кырык мең сум «эшләгән».

ХАЛЫК КҮТӘРЕЛСӘ...

Саратовта яшәүчеләр чираттагы тапкыр хакимиятнең игътибарын шәһәр юлларының хәленә юнәлтергә тырышып караганнар. Алар юлдагы чокыр-чакырлар өстенә гипстан эшләнгән мәче сыннары куеп чыкканнар. Әйтергә кирәк, соңгы елларда монда «халык ремонты» ярыйсы гына еш кулланыла. Ике ел элек шәһәр үзәгендәге чокырларның берсен губернатор портреты белән бизәгәннәр иде, соңрак андый урыннарда һава шарлары барлыкка килә башлады. Ә яз көне җирле фотомодель, юлдагы зур күлләвектә кабартылган фламингога утырып, фотосессия ясады.

ЫСУЛЫН ТАПКАН

Бөекбританиянең Европа союзыннан чыгуына протест йөзеннән, инглиз Уильям Ричес үзенең йортын бәйсез Миддлвоч республикасы дип игълан иткән. Аның фикеренчә, бәйсезлек – Евросоюзда калу өчен бердәнбер мөмкинлек. Республиканың рәсми идарә үзәге итеп ул кухня бүлмәсен билгеләгән, ә прәзидент итеп хәләл җефетен сайлаган. Өстәвенә, йортның чиге аша үтәргә теләүчеләр өчен 50 фунтлык виза каралган. Ә менә икмәк кибетенә барыр өчен аның үзенә Бөекбритания визасы кирәк булырмы – бу турыда Ричес әлегә уйламаган, күрәсең.

ВАК ШРИФТ БЕЛӘН

Британиядә бер провайдер Интернеттан файдалану турында килешенүгә имза куйган клиентлар белән шаяртып алырга булган. Гадәттә, беркем дә укып тормый торган түләүсез Wi-Fi килешенүенә компания «Җәмгыять эшләре» дигән пункт өстәгән. Аның буенча файдаланучыны теләсә кайсы вакытта 1000 сәгатькә эшкә җигүләре мөмкин. Шунда ук эш төрләренең исемлеге дә китерелгән: паркларда хайваннар пычраткан урыннарны чистарту, күчмә бәдрәфләрне тазарту, асфальтка ябышкан сагыз куптару. Әйтергә кирәк, бу пунктны 20 мең файдаланучының бары тик берсе генә укыган.



ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ

Сергей ЕРМИЛОВ



Виктор ФЁДОРОВ



Иван АНЧУКОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Михаил ФРОЛОВ

ГИППОКРАТ ШАЯРТУЛАРЫ

Кешеләр башта акча эшләр өчен сәламәтлекләрен какшаталар, ә аннан соң дәваланырга акча тоталар.

Кеше никадәр өлкәнрәк булса, аның дус табиблары күбрәк.

Операция өстәленә яхшылап беркетелгән авыруга анестезия кирәк түгел.

Хирург – человек, заранее умывающий руки.

Медицинаның яңа казанышлары: күп кенә авырулардан кеше үлми, ә газаплана гына.

Хәзер төрле дарулар шулкадәр күп ки, кеше организмында яңа авырулар табарга өлгермиләр.

Поликлиника – ул авырулар арасында тәҗрибә уртаклашу курсы.

Әгәр бөтен авырулар тәлинкәнең төбендә икән, бәлки, кәстрүлдән генә ашаргадыр?



Рашат НИЗАМИ

АКБУР ҺӘМ ТАЛЧЫБЫК

Нинди шатлыклы көн иде ул! Инде кырык елдан артык вакыт үтсә дә, андагы берничә вакыйга, кино тасмасындагы кебек, күңелдә нык уелып калган.

...Беренче сентябрь иртәсе. Мин, җиде яшьлек малай, зурларча итеп беренче тапкыр мәктәпкә укырга барам.

Әнием мине мәктәпкәчә озата. Безне мәктәп ишегалдында укытучы апа каршы алды. Әнием эшенә китте. Укытучы апа мине өлкәнрәк сыйныф малайлары кулына тапшырды, мәктәп бинасына узарга булышсыннар, янәсе.

Тегеләр, көлешә-көлешә, бер-берсенә күз кысып, мине үзләренә әләктереп тә алдылар. Агач бусаганы атлап, таррак кына коридор уртасына килеп кердек. Буяулары кыршыла төшкән ниндидер ишек каршында туктаттылар мине.

– Шакы, тиз! – диде малайларның берсе, нигәдер көлемсерәп. Тыңламыйча булмый ич инде. Кызык бит. Нәни йодрыгым белән ишек тактасын шакыйм. Ишек дигәнең үзенчә бер тылсым белән ачыла башлаган иде, мине шундук эчкәре төртеп җибәрделәр һәм аркама кинәт, чыжылдатып, ике тапкыр талчыбык белән сыдырдылар! Кулларымда күпме тапкыр чыбык тотып та казларга ник бер тапкыр сукканым булсын минем. Куркудан кычкырып җибәрә яздым.

– Тс-с, шаулама! Шулай тиеш... – диде малайларның өлкәнрәге.

– Шулай тиеш... – дип куәтләде аны икенчесе.

– Син мәктәптә беренче тапкыр, шулай бит?

– Әйе... беренче, – дим, ни икәненә төшенмичә.

– Сине нәрсә белән сыйларга соң? Тукта, – диде бер малай һәм кара такта янындагы тартмадан шикәрдәй ап-ак акбур кисәге тартып чыгарды.

– Аша шуны. Шулай тиеш...

Акбурны мин кулларымда әйләндергәләп тордым-тордым да, ни булса шул булыр дип, авызыма каптым.

– Тиз бул, камырша! – дип ашыктырды мине малайлар, үзләре исә канәгатьлектән буылып көләләр...

Акбур үзе ни ачы да, ни төче дә түгел. Авызымда күпмедер әвәләгәннән соң, мин аны, сытып-ватып, ихтыярсыздан төкрегем белән бергә йотып җибәрдем.

Авыз кырыендагы әлеге сыйның эзләре уелып калган икән, укытучыбыз Зәфәр абый дәрескә кергәч:


– Син нәрсә, энем, мәктәпкә аяк басмас борын акбурга буялып беткәнсең, – дип орышкандай итте үземне.

Мәктәптә беренче тапкыр "чирканчык" алуым әнә шулай тәмамланды. Ә инде, еллар үткәч, олы тормышта чирканчык алу һәм сынаулар әле алда бик күп көтеп торган безне.

Эрнест ДЫШАЕВ, «Чаян» № 14, 1992



Таһир ФӘИЗОВ, «Чаян» № 7, 1991



– Нинди бандит булыйм мин? Суд әле карарын чыгармады!



«Чаян» укучыларын утыз елдан артык журналыбызны җитәкләгән шәхес, журналист, шагыйрь Рәшит ЗӘКИЕВ белән таныштырып торуның кирәге юктыр. Редакция аның белән кулга-кул тотынышып яңа Россия тарихының иң катлаулы борылышларын – торгынлык елларын, үзгәртеп кору чорын, болганчык туксанынчы елларны үтте. Ул «Чаян»ны һәрвакыт үз баласы кебек яратты. Зәкиев үзе бу турыда: «Мин «Чаян» укучыларының барган сукмагын себереп, ишек янында аларны ипи-тоз белән каршылап, йортларына кадәр почтальон сумкасы тотып йөрергә әзер», – дип әйтә иде. Моңа нәрсәдер өстәү кыен...

Бу җылы сентябрь көннәрендә Рәшит Кәрипович үзенең түгәрәк датасын билгеләп үтә. Мондый очракларда, гадәттә, юбилярга сәламәтлек телиләр. Бу яктан аның (Аллага шөкер!) бөтенесе дә тәртиптә булуга карамастан, без традицияләрне бозмаска булдык. Корычтай сәламәтлек һәм озын гомер сиңа, хөрмәтле аксакалыбыз!

ЧӘЧЕП ТОРА...

Дус дигәндә, ул йөзеннән
Гел нур гына чәчеп тора.
Мич башында мичкә белән,
Гуя, балы әчеп тора.

Хәлен белеп сәлам бирсәң,
– Ни йомыш? – дип дәшеп тора.
Сәлам сүзен тизләтергә,
Ашыктырып тамак кыра.

Йомыш төшсә, кире какмый,
Башын гына читкә бора,
Син, янәсе, көтеп торма,
Башкалардан ярдәм сора.

Үз кирәге чыкса әгәр,
Дус җирендә урак ура.
Әрсез диеп уйлый күрмә, –
...Дус дигәндә, ул йөзеннән
Гел нур гына чәчеп тора...

И ГОМЕРНЕҢ АГЫМ СУЫ...

Дуслар әйтә җайлап кына:
"Кырык сиңа, кырык сиңа..." –
Бер карасам, кызык сыман,
Бер уйласам, курыксынам.

Соң, Илгизәр, әле гәпне
Кордык кына, кордык кына,
Каян булсын ди ул кадәр?! –
Кырык миңа, кырык миңа?

Без бит яңа баш калкытып
Тордык кына, тордык кына,
Чишмә суы белән битне
Юдык кына, юдык кына.

Әйтүендер, Марсель туган,
Бу сүзләрне кызып кына:
– Абзаң булып көнлим синнән,
Сиңа бары кырык кына.

Ышанмас идем бу хәлгә,
Хатын тамак кырып тора:
– Ни яшәрсәң дә, җан кисәк,
Кырык тула, кырык тула.

И гомернең агым суы,
Ул ерасын ерып тора...
Кая качасыз, чибәрләр?
Безгә әле кырык кына!..

АЛАЙ ГЫНА ИТТЕҢ, БОЛАЙ ГЫНА ИТТЕҢ...

(төрле көйләргә җырулар)

• • •

Тышта гына, ай, җилләр җиләс,
Өйгә керсәм, тыштан нык җиләс.
Ник басылмый икән, ник басылмый
Котельныйдан килгән бу җиләс?

...ЖЭКларыннан тун таптырмый булмас,
Тун бирсеннәр, җылы бирмәгәч.

• • •

Ак та гүрничәнең эчләрендә
Кара савытларың пыяла.
Кара манчып язган сүзләреңнән
Кәгазь бите хәтта ояла –
Кем өстенә төшәр бу яла?!

• • •

Өске катка су менәсе, диләр,
Ышанмыйм мин имеш-мимешкә –
Иртә белән бардым инешкә лә,
Кичтән тагын бардым инешкә.

• • •

Алай гына иттең, болай гына иттең,
Биек абзар салдың малларга.
Үрнәк алыйк, диеп, җиде төштән
Кунак килде абзар карарга.
Абзар гынаең, ай, саз гына,
Аяк басар төше аз гына.

БИШ ЭСКЕРТ ПЕЧӘН

Кояш нур чәчә,
Җилләр дә исми.
Агроном Хисми
Чәчәкләр исни.

Чәчәк мең төрле,
Аллы да гөлле,
Кызлар такыя
Үрерлек инде.

Суырган чәчәк
Басуның ашын,
Исе исертә
Агроном башын...

"Ни кылырга соң
Бу чәчкә белән?
Чалгы ярарлык,
Ярамас китмән".

Хисми өндәгәч,
Басу гөр килә.
Чыңлый чалгылар,
Әй, кыза өмә!

Кояш нур чәчә,
Җилләр дә исми,
Отчет тутыра
Агроном Хисми:

"Уталды басу,
Уталды чүптән,
Җыйдык хәтта без
Биш эскерт печән..."

...Шәп булды өмә,
Өмә гөр килде.
Чүгендер кыры
Тап-такыр инде.

Татлы тамырлар
Үсмәс, көчәнмә, –
Чәчәк ярады
Бары печәнгә.

• • •

Ашханәгә кердем, сыйланыйм, дип,
Кашыклары майлы – тоталмыйм.
Авыз тутырып ашын капкан идем,
Ашкайларын, ай-һай... йоталмыйм.
Бөдрә тал,
Биргән акчам
Бигрәк жәл...

Җыруларны Рәшит ЗӘКИЕВ язып алды.

БАРЫСЫ ДА АҢЛАШЫЛДЫМЫ?


Житәкче авыл кешеләренә жирдә нәрсәләр төзеләчәген аңлата:

– Хәзер бер авыл хужалыгы белән генә яшәп булмый! Бүгенге көннең таләбе шундый. Шуңа күрә монда безнең үтә куәтле технологик кластер булачак, ә монда – логистик хаб, тегендә коворкинг мәйданы, әнә тегендә инжиниринг һәм консалтинг, ә елганың аргы ягында – краудфандинг платформалары оештырылачак. Берни дә онытылмады бугай...


– Әйтегезче, ә ашарга берәр нәрсә булачакмы соң? – дип сорый берәү. – Бәлки, бөтенләй ачтан үлмәскә берәр сыер йә тавык фермасы төзергәдер?..

– Ә, әйе, ферма... Оныта язганмын! Ә-ә-әнә тегендә майнинг фермасы, ә янәшәсендә сартрап инкубаторы булачак. Бөтенесе дә әйбәт аңлашылдымы? Аңласагыз – жиң сызганып эшкә!

Кәрим СӘЛАХОВ







Илзирә ВӘЛИУЛЛИНА

“ЯШЬЛЕКНЕ КАЙТАРАБЫЗ...”

Галимнәр картайтмый торган
Дару уйлап тапканнар.
Тәжрибәдән соң хәтта ки
Яшәргәннәр тычканнар.

Ошбу даруны кулланган,
Карт күзәнәк үлә, ди.
Алмашка карт урынына
Яңа, яше килә, ди.

Малышевага да диләр,
Хатлар килгән күп жирдән.
Котылырга теләүче күп
Картлыкка бәйле чирдән.

Картаюдан дәва юк дип,
Уйлап йөрүче белсен:
Яшьлеген кайтарыр өчен
Түләп, бүлнискә килсен...

РӘХМӘТ ЯУСЫН


Котырына басуларда иген,
Сәгать саен арта савымнар,
Үрләр яулый авыл хужалыгы –
Адым саен – яңа алымнар;
Мартеннарда утлы корыч ургый,
Тыелгысыз үсә автопром,
Һава яра яңа самолётлар,
Гомумән, ил – гүя аэродром:
Гөрләп тора завод-фабрикалар,
Ил байлыгы аша күкләргә.
Балда-майда йөзә гади халык –
Рәхмәт яусын санкцияләргә!

Ринат АБЗАЛОВ

Виктор ФЁДОРОВ



Вячеслав БИБИШЕВ





Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Кытайның үз ике бәласе – сан ягы һәм сыйфат мәсьәләсе!

• • •

– Юкка-барга иң нык ышанучы терлек иясе – тукран белән дөя.

– Нигә алай?

– Берсе бертуктамый агач тукый, икенчесе һәрвакыт төкерергә маташа.

• • •

– Син миңа гади карандашыңны биреп тормассыңмы?

– Мә, ал.

– Бу бит кызыл.

– Ә, нәрсә, кызылы бик катлаулымы әллә?

• • •

Иблис белән килешенү – кредит алган сыман. Башта аласың, аннан бирәсең. Аллаһы Тәгалә белән килешенү – пенсия кебек. Гомер буе бирәсең, йә соңыннан алырсың, йә бөтенләй алмассың да.

• • •

Сихер салонына бер ханым керә һәм үзеннән бозыкны алуны сорый.

– Сездән мең доллар...

– Шулай кыйбатмы? – ди, әмма акчасын бирә.

– Бозык алынды. Сау булыгыз!

– ???

– Акча кешене боза, тагын килегез, сезгә ярдәм күрсәтергә без һәрвакыт әзер.

• • •

Бер сайтны ачтым: "Теркәлегез һәм бушлай яхшы сыйфатлы фильм карагыз!" Икенчесен ачтым: "Теркәлегез һәм бушлай китаплар күчерегез!" Сез акылдан яздыгызмы әллә? Мин бит әле аерылыштым гына!

• • •

Айфон-8 үзенең хуҗасын йөзеннән таный һәм әгәр бу йөз аңа таныш түгел икән, шундук барлык нәрсәләрне томалый. Болай итеп, иртән ярты илне элемтәсез калдырырга мөмкин бит.

Ринат АБЗАЛОВ



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Алиш КОРБАНОВ

БИЗНЕСМЕН БАРИ

– Бизнес белән шөгыльләнәсем килә, – дип әйтеп салды миңа күршем Бариулла. Бу сөйләшү ял көнне вокзал каршындагы сыраханәдә булды.

– Нәрсә белән? – дидем мин, бик аңлап бетермичә.

– Бизнес белән, – дип кабатлады Бари бу сүзне бик тәмле итеп.

– Синме?

– Мин, – дип куйды ул, канәгать елмаюын күрсәтеп. Бари тимерчеләр цехында эшли. Эше авыр, пычрак. Тиеннәр генә түлиләр. Шулай да җитәкчеләр онытмый. Даими рәвештә Мактау кәгазьләре белән бүләкләп торалар. Әмма беркайчан да премия бирмиләр. Алар үзләрен генә бүләклиләр, чөнки тегенди-мондый сәер алдынгылар күптин-күп.

– Нишләп соң әле тиктомалдан бу фикергә килдең син?

– Ничек килмим, ди? – Барига үпкәләгән төс керде. – Мин бит инде айлар буе уйлап йөрим бу турыда. Тиенгә эшләп йөрү туйдырды. Тукранмы әллә мин аларга? Минем дә күп акча эшлисем килә!

Менә шундый булып китте Бари! Болай карап торырга тинтәгрәк булып күренсә дә, озын колаклы башында нинди кайнар уйлар гөрли бит!

– Ә син ул акчалар белән нәрсә эшләмәкче буласың? – дип сорап куйдым, аңа җентекләбрәк карап торгач.

– Акчасы булса урыны табыла аның, – дип тынычландырды ул мине. – Иң элек "мерс" сатып алам. Ул миңа офиска килеп туктарга кирәк. Һәм аяклары колагына хәтле булган секретарь кыз алам эшкә. Ә ял көннәрендә Канар утрауларына очам!

– Хатыныңны үзең белән алмыйсың, димәк?

– Тулага үз самавырың белән бармыйлар! – дип көлемсерәп куйды ул. – Хатын өйдә утырсын. Безнең шәһәр читендәге фазендада. Баштан-аяк ефәк һәм кеш мехыннан затлы караватта мине көтеп ятсын.

– Әйе, Бариулла, сине искиткеч гүзәл киләчәк көтә! – дидем мин, аңа карап. – Хәтта сулыш каба! Ә соң бизнесыңда син нәрсә белән шөгыльләнмәкче буласың?

– Нефть белән! Нефтьтә бик тиз үрләр яулап була. Беренче хезмәт хакыннан ук яхта сатып алам...

– Нигә нефть белән? – дип гаҗәпкә калдым мин. – Анда бит күптән бөтенесе бүленеп беткән! Анда читләр керә алмый...

– Ярый, мин сиңа серемне ачам, – диде булачак нефть магнаты, колагыма пышылдап. – Күршем нефть базасында – каравылда эшли...

– Алай булса аңлашыла! Канар, мерс синең кесәңдә дип чутлыйм! Әйдә, шул очрактан тагын бер кружка сыра җиппәрик, сәбәбе бар!

Булачак бизнесмен кесәсеннән вак акча эзләргә кереште...

СӨЮ АРИФМЕТИКАСЫ

Миңа – илле.
Сиңа – егерме биш.
Шатландырмый ләкин яшьлегең:
Кочалмамын хәтта йөз утызда
Хатыннарның йөз биш яшьлеген!

ШАШКЫН ТӨННӘР

Аһ сез, шашкын сөю тулы төннәр...
Тик яшь бара, калдым соңгарак...
Шуңа күрә якын ул төннәрнең
Җәйгеләре – алар кыскарак.

Ринат АБЗАЛОВ



Игорь КИЙКО



Николай ВОРОНЦОВ

Мәгариф министры ун тапкыр БДИны тапшыра алмаган, сәламәтлек саклау министры поликлиникада чиратта һушыннан язган, ә бер депутат 6 мең сум пенсиягә яшәп, ачтан үлгән. Бары тик шуннан соң гына пенсионер балыкчы алтын балыкны ирекккә җибәргән.



Игорь КИЙКО




ДЗИНЬ!


Бүген мәктәпкә! Әйберләреңне әзерлә...




Дәфтәрләреңне онытма!


Бүген сезнең физкультура...



Әйе, гантельләр алып килергә куштылар!













Александр АЛЁШИН



ҖӘЯҮЛЕЛӘР ЗАРЫ

Бичурин урамындагы 11 нче йортта ачылган "Пятерочка" кибете җәяүле сатып алучыларга исәпләнмәгән, күрәсең. Аны башкача аңлатып та булмый, чөнки кибет мәйданы янында бер генә җәяүлеләр юлы да юк. Кибеттән чыгуга – парковка, аннан тимер койма белән әйләндереп алынган. Сатып алучыларга, кибеттән чыккач, машина юлыннан тәпиләргә генә кала.

Ә менә машиналары булган халыкка бөтен шартлар да тудырылган: зур, иркен парковка, борылыйм дисәң, киң мәйдан... Зур сумкалары белән машина арасында буталган халыкка көнләшеп карарга гына кала...

В. ӘБДЕЛМӘНОВ

КАЗАН

ҖИР АСТЫ МӘХШӘРЕ

Соңгы араларда башкалабыз күзгә күренеп матурланды: яңа парклар калкып чыкты, яңартылган, заманча эшләнгән елга буйлары, Кремль, тарихи урыннар туристларны үзенә тартып тора. Ләкин бу әле ал да гөл дигән сүз түгел. Мисал өчен, елга буена чыккан җир асты юлында бер генә лампочка да янмый. Кремль матурлыкларына сокланырга теләүче халык, капшана-капшана, кесә телефоннарын яктыртып йөрергә мәҗбүр. Имеш-мимешләргә караганда, яктырткыч утлар булган икән, ләкин аларны хулиганнар ватып бетергән. Халыкка уңай шартлар тудыру хезмәтенә аклану өчен сәбәп түгел болар, чөнки ватылмый торган лампалар күптән уйлап табылган бит инде.

Ә хәзергә, кунаклар алдында гафу үтенеп, киләчәктә уңай шартлар җир асты юлларына да төшеп җитәр дигән өметтә калырга туры килә.

А. САФИНА

КАЗАН

ЧИЛЕ-ПЕШЛЕ ЗАКОН

Кадерле редакция! Мин – тәҗрибәле бакчачы. Җиләкне кайчан җыярга, колорадо коңгызын кайчан җыярга, җирне кайчан йомшартырга һәм уңышны кайчан җыярга – боларның барысын да бик яхшы беләм һәм төгәл үтим. Халык әйтмешли, ашыккан ашка пешкән...

2019 елның 1 гыйнварыннан 6 сутый җирләре булган халыкны яңа үзгәрешләр көтә. Ул да булса: бакчачылык җәмгыятендә яңа үзгәреш-канупнар. Дәүләт Думасында әлеге проект күптән каралып килә иде инде, өлгереп кенә җитә алмый. Үзегез уйлап карагыз, бакчачылык җыелышлары халыкның яртысыннан артыгы катнашуны таләп итә, алай булмаган очракта дөрес түгел дип санала. Шәһәр буйлап сибелгән халыкны бер урынга һәм бер вакытка җыйганчы, бер капчык чәчелгән борчак җыеп алуың җайлырак, дияр бакчачылык рәисләре әлеге үзгәреш хакында.

Бигрәк тә әлеге җыелышлар бакчачылык мәйданында гына уздырылырга тиеш дигән пунктка басым ясыйлар. Ә нишләп әле менә март-апрель айларында – коры берәр бинада җыелмаска? Бата-чума пычрак ерып йөргәнче?..

Ләкин бакчачыларны банкротлыкка чыгу куркынычы сагайта. Ул очракта бит җыелыш та "легитим" була алмый. Утка-суга бурычка батасыңны көт тә тор. Ул очракта, җәһәт кенә банкрот ясап, 6 сутый җиреңнән дә колак кагуың бар.

Кемгә кирәк булды икән чиле-пешле әлеге закон? Бәлкем, җир дип, күзләре тонган эшем кешеләренәдер? Ничек кенә булмасын, ләкин гади бакчачылар хәлен алар авырлаштыралар гына...

Р. ИШБУЛАТОВ

ЧАЛЛЫ





Маннур САТТАРОВ

БАЛА АШАТУ ҖЫРЫ

Әлли-бәлли итәргә
Үз әнкәсе бар аның.
Кыстый-кыстый ашатырга
Ун нәнкәсе бар аның.
Калак тоткан әнкәсе,
Табак тоткан нәнкәсе,
Алма тоткан апасы,
Кәнфит тоткан әткәсе,
— Ашамасаң, мин ашыйм, — дип,
Авызын ачкан әбкәсе.
Тыпыр-тыпыр биииләр,
Бар да көен көйлиләр.
— Тамагы туктыр, — димиләр,
— Ник ашамый бу? — диләр.
Җайлап карый әнкәсе,
Янап карый әткәсе,
Идән буйлап, кашык тотып,
Куып йөри әбкәсе.
Артларыннан табак белән
Ботка сөйри нәнкәсе.
Песи баскан каршына,
Вау-вау качкан артына,
Мин ашыйм да, мин ашыйм дип,
Килеп җиткән барсы да.
"Мияу-мияу!" апасы,
"Кыйгак-кыйгак!" атасы,
"Бак-бак-бак-бак!" әбкәсе,
"Кыт-кыт-кыт-кыт!" әнкәсе,
"Китегез сез, үзе ашый", — дип,
Куып тора нәнкәсе.
Әбкәсенә ач кебек,
Нәнкәсенә тук кебек,
Әнкәсенә атна буе
Капканы да юк кебек.
Чәбәк-чәбәк әнкәсе,
Чыбык эзли әткәсе,
Борып-борып чеметергә
Җан көтә нәнкәсе.
"Кыйнамагыз, ашый ул", — дип,
Аерып ала әбкәсе.
Җиде төрле аш кына,
— Аша, балам, чак кына.
Бала, мескен, кашык күрсә,
Кача өстәл астына.
— Авырыйдыр, — ди әнкәсе,
— Врач дәш, — ди әткәсе.
— Врач нәстә белә соң ул,
Өшкертик, — ди әбкәсе.
Барысын тотып өшкерергә
Кызыгып тора нәнкәсе.

Валерий ТАРАСЕНКО





Василий АЛЕКСАНДРОВ

Антон МАКУНИ

110% – ГАРАНТИЯ!

Кичә салым бүлегендә ике эшкуар сөйләшә. Берсе болай ди:

– "Татьфинтбанк"ның башлыгын тотканнар икән, бөтен сарай һәм яхталарын саталар... Инде хәзер безнең шунда салган акчаларны кайтара башларлар!

– Кит аннан?! Акча артыннан кая чабарга соң? – дип сорый икенчесе, шаккатып.

– Акчалата кайтармыйлар, җир бүлемнәре бирәчәкләр. Аның өчен җир комитетына барырга кирәк, ди.

Әлеге сөйләшүне тыңлап тордым да, шунда очтым. Чөнки минем ачкан фирмамның акчалары шул банкта янып маташа.

Комитетка килсәм, халык Сабантуйга җыелган кебек. Йөз мең дә беренче булып язылдым...

Халык гөр килә. Бер ир болай ди:

– Җир инде күптән үзләренеке арасында бүленеп беткән. Безгә көрәк белән казып булмый торган калдык җирне генә калдырганнар, кәйләсез эшкәртеп булмаячак!

Чаптым кәйлә эзләргә. Ник бер хуҗалык товарлары кибетендә булсын ул. Банктан җәфа күргән эшмәкәрләр сатып алып бетергәннәр. Базарга киттем. Ә анда эшмәкәр кыяфәтендәге ике хатын сөйләшеп тора:

– Ишеттеңме, – ди берсе. – "Татьфинтбанк"тан янганнарга акча бирәләр...

– Акча түгел, – дип җавап кайтара икенчесе. – Нефтьләтә кайтаралар! Һәр кешегә берәр кисмәк!

Мин аларны озак тыңлап тормадым, чебен тизлегендә нефть базасына очтым. Ә андагы халык – футболдагы кебек! Йөз мең дә икенче булып язылдым... Үзеңнең кисмәгең белән килергә иде, диләр. Чаптым кисмәк эзләргә. Бер җирдә юк. Күрәсең, банктан янганнар алып бетергән. Кабат нефть базасына кайттым. Ә анда нефть тармагының начальнигы чыгыш ясый:

– Нефть безнең казанышыбыз, байлыгыбыз, шуңа күрә бүленергә тиеш түгел! – ди.

Халык, ризасызлык белдереп, шаулашкан булды да таралышты. Өйгә кайткач, вак хәреф белән язылган банк килешү кәгазен алдым да яндырдым... Көле күп чыкты. Чарасызлыктан башыма шул көлне койдым һәм... ышанмассыз, могҗиза! Пеләшемә чәч үсә башлады! Бу көлне яңадан капчыкка җыйдым да, "Теләсә кайсы урында йон яки чәч үстерә алам, 110% - гарантия!" дигән белдерүләр бирә башладым.

Һәм шуннан китте-китте, чаба башлады. Пеләш башлылар күп бит алар! Акча белән бөтен матрасларны тутырып бетердем! Әгәр сезнең дә банк килешү кәгазьләре булса – җыям. Үлчәп тә алам, берәмтекләп тә... Минем бу көлле эшмәкәрлегем беркайчан да янмаячак! Дәүләт гарантияли!

Максим СМАГИН



Илдар НӘФИЕВ



Валентин ДУБИНИН





Ринат БӘШИРОВ



Александр КОСМЫЛИН



• • •

– Кадерлем, сиңа ике яңалыгым бар!

– Нинди?

– Начары – синең бөтен акчаңны туздырып бетердем. Яхшысы – хәерче булсаң да, сине барыбер яратам.

• • •

Нинди хәл бу? Кәҗә арыслан белән дуслашкан, бүре – ишәк белән, кешеләр генә тыныч яши алмыйлар!

• • •

Хатын-кызның хыялы: их, ирләр күп акча эшләп, гомер буе аларны кулларында гына күтәреп йөртсәләр икән. Ничек итеп эшләсен ул аны, куллары беркайчан да буш булмаса?

• • •

Мәхәббәт өчпочмагында бер генә почмак — гомуми кулланыштагысы.

• • •

Рәсәйнең өчтән бер пенсионеры август аеннан 220 сум өстәмә акча алды. Инде сатып алырга яхта эзләп йөриләрдер!

• • •

– Үзең сау-сәламәт, ә үзең хәер соранасың. Эшләргә тырышып карамадыңмы?

– Соң, мин бит эштән соң...

• • •

Хатыны иренең яшереп куйган акчасын тапкан.

– Бу акчалар кайдан?

– Менә сиңа бүләккә әйбер алырмын дип җыйган идем...

– Ә нишләп бик аз?!

• • •

– Миңа кияүгә исәп-хисап итеп чыктыңмы?

– Әйе. Тик менә нәрсәгә исәп итеп чыкканымны хәзергәчә аңлый алмыйм!





Ут белән уйнау

Баланың үсмер чагы узганчы, ата-аналар аның өчен кайгырып, егерме яшькә картая, диләр. Ярсыган гормоннар, тормыш тәҗрибәсе булмаудан тагын да көчәеп, әти-әнигә дә, яшь организмга да, хокук саклау органнарына да тынгы бирми. Соңгыларына, республикада яшүсмерләр арасында җинаятьчелекнең кимүенә карамастан, барыбер эшсез калырга туры килми.

Сәер хәл, тик криминалга беренче адымнарын яшүсмерләр Интернетта ясый. «Олы тормыш» гүзәллеген татып карау теләге еш кына аларны бөтендөнья челтәре аша наркотик таратучыларга китерә. Җәйге каникуллар вакытында Казан полицейскийлары «контактсыз» сату өчен яшерен урыннарга синтетик наркотиклар куеп йөрүче бер төркем укучыларны тоткарлаганнар. Ул вакытка аларның үзләре белән 9 грамм исерткеч матдә калган булган. Әлмәттә исә шул ук шөгыль өстендә 46 грамм белән дүрт яшүсмерне тотканнар. Аларга әле 16 яшь тә булмаган. Бу очраклы хәл түгел: наркоиндустрия «йөкчеләренә» карата бу яшьтә әле җинаять эше кузгатылмый, административ чаралар гына кулланыла.

Катлаулы тормышның төрле якларына аек бәя бирә алмаганлыктан, алар үзләре белгәнчә күңел ачалар. Яраган нәрсә белән шөгыльләнергә инде теләк юк, ә теләгәнең белән – әле ярамый. Күптән түгел полицейскийларга Татарстан буенча диярлек үсмер машина каракларын куарга туры килгән. Мамадыш районында бер «Ауди»ны «иярләп», алар, барлык юл патрульләре аша узып, Казанга барып җиткәннәр, ә аннан Түбән Камага элдерткәннәр. Ирекккә чыккан яшь «айгырларны» юлны томалап кына туктатканнар.

Кайчагында яшүсмерләр, бөтенләй акылдан язып, җинаять кылуга ук барып җитәләр. Яшел Үзән районының Малые Ключи авылыннан берәү үзенең үлемен улы аркасында күргән. Тегесе, әтисендәге җир документларын кулына төшереп, аларны «кара» риэлторлар аша сатмакчы булган.

Мондый хәлләр белән чагыштырганда, бер Казан малаеның үен салонында төсле принтерда үзе бастырып килгән өч «иллелек»не «төртергә» маташуын балалар уены булып кына тоела.

Шунысы кызык, сорау алу вакытында ут белән уйнаучы мокытларның бу уеннарның нәрсәгә китерергә мөмкин икәне, турында уйлап та карамаганлыклары ачыклана. Болар өчен хафага төшкән ата-аналарның һәм аптырап беткән хокук саклаучыларның гына кайгыртасы кала...

Людмила САФИУЛЛИНА



Александр АЛЁШИН



КӨЛКЕ КАМЕРАСЫ

Николай ВОРОНЦОВ



Александр КОСМЫЛИН



• • •

– Нигә элек җинаятьләр хәзергегә караганда кимрәк булган икән?

– Чөнки «Место встречи изменить нельзя» фильмын бөтен бандитлар да караган. Ә менә «Глухарь»ны хәзер – ментлар гына...

Александр СЕРГЕЕВ






Илдар НӘФИЕВ




Яшәгәннәр, ди, төлке белән куян. Куянның өе агачтан, ә төлкенеке боздан булган, ди. Яз җиткәч, төлкенең йорты эреп аккан.

– Менә сиңа мә! дигән төлке. – Ә минем аның өчен әле дүрт ел ипотека түлисем бар!

Ринат АБЗАЛОВ



Сергей АНДРИАНОВ



Казан тарихы БИТЛӘРЕННӘН

РӘСӘЙНЕҢ ЧӘЙ МӘРКӘЗЕ

Бездә шундый гыйбарә бар: татарның өстәлендә һәрвакыт чәй, чәкчәк һәм бәлеш торырга тиеш. Күргәнебезчә, чәй монда беренче урында тора. Һәм бу очраклы түгел. Чәй эчү татарларда гаилә гореф-гадәтләренең иң мөһим өлеше һәм кунакчыллык билгесе булып саналган. Бу йола каян һәм ничек килеп чыккан соң?

Билгеле булганча, бу хуш исле эчемлекне татарлар, русларга караганда, алданрак татып караганнар. Чөнки алар күп сәяхәт иткәннәр, читтә сәүдә белән шөгыльләнгәннәр, шуңа күрә көнчыгышта чыккан чәй эчү йоласы белән күптәннән таныш булганнар. Тик Казанда чәйне XVII гасырның икенче яртысында гына сата башлаганнар. Аны дөяләр һәм атлар белән Монголия аша Кытайдан кайтарганнар. Юл ерак булган – 11 мең чакрымны үтәр өчен ул вакытта бер ел кирәк булган.

Яңа эчемлекне башта дәвалау чарасы буларак кулланганнар. Тора-бара, чәй сәүдәгәрләр һәм мөселман руханиларының күңеленә хуш килгән, бераздан ул халыкта да киң таралган. Башта аны зур бәйрәмнәрдә генә эчә торган булганнар, чөнки чәй бик кыйммәт булган. Ул чакларда "Шифа бирә җанга чәй, тик бәясе ай-яй-яй!" дигән әйтем дә йөргән. Казан татарларының тормышында "чәйгә чакыру" гадәте XVIII гасыр уртасында төп урын алган. Йортка кунак килгәч, көннең кайсы вакыты булуына карамастан, һәрвакыт чәй куйганнар. Таныш-белешләргә чәйгә йөрү – мөселман хатыннарының бердәнбер вакыт уздыру чарасы булган. "Чәй эчкән – йон эрләвен оныткан" әйтеме дә шул вакытта барлыкка килгәндер.

Чәй эчү йоласы мондый булган. Чәйне, гадәттә, хуҗа ясаган, кунактан сорап, сөт өстәгән. Фарфор чәйнектә бик каты итеп пешереп, суынмасын өчен самавыр өстендә тотканнар. Самавыр һәр өйдә булган һәм аны сату хәерчелеккә төшү билгесе булып саналган. Казан татарлары бу эчемлекне сөт, бал, күрәгә, кара җимеш, как белән эчкәннәр. Өстәлдә һәрвакыт төрле-төрле чәй ашлары торган.

Татар авылларына чәй соңрак килгән. Гади халык такта чәйне бик үз иткән. Аны, каты итеп, һәрвакыт сөт салып эчкәннәр. Авылда шулай ук "алма чәе" киң таралган булган – аны киптерелгән алма, бөтнек, мәтрүшкәдән ясаганнар.

XIX гасырда чәй эчү Казан татарларының тормышында гадәткә кергән. Аннан башка туй мәҗлесе, бәби туе һәм башка бәйрәмнәрне күз алдына да китерү кыен булган. Һәр өйнең иң түрендә һәрвакыт самавыр һәм фарфор чәй чынаяклары торган. Татар бистәләрендә яшәүчеләр чәйне Печән базарында сатып алганнар. Ул анда иң популяр һәм күп сатыла торган товар булган. Әйтергә кирәк, казанлылар яхшы чәйне таный белгәннәр. Гомумән, шәһәр Рәсәйнең чәй мәркәзе булып саналган.

Татар ашамыйча тора ала, чәй эчмичә яши алмый, диләр. Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев әйтүенчә, ул эчемлеккә мәхәббәт безнең каныбызга сеңгән һәм буыннан-буынга күчеп бара. Хәзер дә аны беренчесен соклар белән алыштырып булмый...

Адым саен авызга керәм дип торган кока-колалар һәм фанталар заманында да чәй татарның сөйгән эчемлеге булып кала, ә борынгы "чәйгә чакыру" гадәте инде өч гасыр буе халыкта яши бирә.

Валентин ДРУЖИНИН






Михаил ЛАРИЧЕВ




Чит ил басмаларыннан шаян рәсемнәр

Павел КАЧИНСКИЙ (Польша)



КОВЕРЛА (Бөекбритания)





Мирослав БАРТАК (Чехия)



Анхель БОЛИГАН (КУБА)

Cartoonblues.com., BizarroComic.Blogspot.com



• • •

Табиб-косметолог пациенткасына борынгы грек профиле ясаган: җыерчыкларын тигезләгән, ике ияклеген бетергән, авызын кечерәйткән.

— Ә минем күзләремне зурайта аласызмы? — дип сораган аннан пациенткасы.

— Әлбәттә! Счетка карагыз!

• • •

Әгәр дә сез почта ящигында "повестка" яки "военкомат" дигән сүзләр язылган хат күрсәгез — ачмыйча ук ертып атыгыз. Анда куркыныч вирус бар, ул сезне Интернеттан һәм компьютердан бер елга мәхрүм итәргә мөмкин.

• • •

— Алло, югалган этегезне тапкан кешегә бүләк бирәм, дип белдерү биргән кеше сезме ул?

— Әйе! Сез аны таптыгызмы?!

— Юк әле... Ләкин аванс аласым килә.

• • •

— Нәрсә өчен Интернетны күрә алмаслык дәрәҗәгә җитү мөмкин?

— Һәрвакыт бәрәңге көйгән, пилмән таралып беткән өчен һәм суынган чәй өчен!

• • •

Ике дус хатын сөйләшә.

— Бер биш ел элек ирем белән икебезгә бер алдакчы карчык, үзен асрауга алып, фатирын безгә калдырырга тәкъдим иткән иде.

— Ә нишләп ул алдакчы?

— Соң ул бит әлегә кадәр исән-сау.

• • •

Менеджер Петров үз гомерендә бер мәртәбә иң уңышлы килешенү башкарды — коллегасының туган көненә 200 сум биреп, 500 сумлык пирогын ашады.

ЧуАр пресса

БӨТЕНЕСЕ ДӘ КАГЫЙДӘ БУЕНЧА

Шотландиядә бер ферма хуҗаларының бик күп тавыклары булган. Тик бер ягы уңмаган – ферма янында зур юл узган. Тавыкларның куркынычсызлыкларын тәэмин итү өчен хуҗалары әкәмәт чара уйлап тапканнар – кошның һәрберсенә яктылыкны кире кайтара торган тасмалы жилетлар кигертеп чыкканнар.

ҖӘННӘТКӘ ХАТ

"Одесса – Сортировочная" локомотивлар депосында көлкеле очрак булган. Кайчандыр үзләрендә эшләгән Гладуковка кадрлар бүлеге, хезмәт кенәгәсен кереп алырга дип, хат җибәргән. Хикмәт шунда: тимерьюлчы 2011 елда ук вафат булган.

БӘЯЛӘНМӘГӘН

Франция чемпионатының чираттагы турында "Ницца" футбол клубы "Генгам" клубын кабул иткән. Бөтен кешенең күңелен һөҗүм итүче Вальтер күтәргән. Ул ике тайм буе футболкасыннан бәя биркасын алмыйча чабып йөргән. Болай итеп, клуб җитәкчеләренә, ала торган гонорарына караганда, футболкасының бәясе күпкә югары икәнен белгертәсе килгәндер.


НАДАННАР

Географияне начар белүләре "Россия-24" телеканалында эшләүчеләрне уңайсыз хәлдә калдырган. Якутиянең ерак районнарына оча торган яңа медицина модуле булган МИ-8 вертолёты турындагы репортаж вакытында экранда вакыйганың урыны "Республика Саха (Япония) дип күрсәтелгән була.


ЯЗЫЛ ҺӘМ ҖИҢЕП ЧЫК!

Бүләгебез хуҗасын тапты – аңа Башкортстаннан Илдус Фазлетдинов лаек булды. «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең биелгы нәтиҗәләре буенча иң актив абунәчеләр арасында уздырган конкурста ул җиңүче дип табылды. Илдус төп бүләк булган телевизор отты! Җиңүчене котлыйбыз! Исегезгә төшерәбез: конкурс дәвам итә, димәк, һәркемгә бәхет елмаерга мөмкин. Язылыгыз һәм җиңеп чыгыгыз!





Валентин ДРУЖИНИН




Вячеслав ШИЛОВ

Чаян автосалоны


?!

АВТОВОРД


1


2


3



4


5



6


7


8














9


Горизонталь юлларга таныл- ган автомобиль маркаларының исемнәрен языгыз һәм вертикаль юлда тагын бер марка исемен укы- гыз.



Җаваплар: 1. Мазда. 2. Мустанг. 3. Опель. 4. Ситроен. 5. Феррари. 6. Шевроле. 7. Пежо. 8. Бентли. 9. Дацун.

ИКЕ БЕРТӨРЛЕ АВТОМОБИЛЬ ТАП



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 9 (1863) 2017

«ТАТМЕДИА» АЖ филиалы җитәкчесе
һәм баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**
Баш редактор урынбасары, баш рәссам:
Александр АЛЁШИН
Үсеш бүлеге:
Павел СТАРОВЕРОВ
Җаваплы секретарь: **Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА**
Бүлек редакторлары: **Людмила САФИУЛЛИНА**
Артём СУББОТКИН
Алмаз ХӘМЗИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: **Ләйсән ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.

Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2

«Чаян»га Татарстанда, Россиядә һәм БДБда барлык элемтә бүлекчәләрендә һәр айдан язылырга мөмкин.

Татарстанда яшәүче укучыларыбыз журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.
Бу очракта язылу индекслары русча П2440, татарча П2438.
«Агентство «Роспечать» Каталогында индекслар: 73489 – рус, 73488 – татар телендәге журнал өчен.
Аның буенча Россия һәм Татарстан укучылары язылa ала.

Айга бер тапкыр чыга.

Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килмәскә мөмкин.

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.

Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.
«Чаян»нан икәнен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.
«ТАТМЕДИА» АЖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басарга кул куелды: 5.09.2017 ел.
Гомуми тираж −3290
(рус. − 1973, тат. − 1317)
Заказ А-2163
Кәгазь форматы 84x108 1/16.
Офсет ысулы белән басыла.
Басма табагы 2,1.
Учетн.-изд. табагы 3,1.



Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00,
тел./факс: 222-05-54.

16+

E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

Бәясе ирекле

Күкәй казасы

Лерон ФАЗЛЫЕВ

Харис абзый каз оясыдай йомшак ятагында йоклап ята. Озак та узмый, йокы бүлмәсендә яшьлектә Күгәрченем дип кенә йөрткән хатыны, ә лаеклы ялга чыккач, ыслап йөрүче Ыслания пәйда була.

– Син гимн уйнаганны ишетмәдеңме әллә? – дип, Харисның юрганын тарткалый башлый.

Юрган астыннан ишетелер-ишетелмәс кенә:

– Минем эшкә барасым юк бит, – дигән тавыш ишетелде.

Ыслания, кырт борылып бүлмәдән чыгып китүгә, дәррәү кире әйләнеп тә керә.

– Мин сиңа соңгы тапкыр әйтәм, тор, дим. Кырынып, юынып, тамагыңны туйдыр да базарга барып күкәйләр алып кайт. Узган атнада алганнарың бик вак булды, күзлегеңне киеп, әйбәтләп карап ал. Күкәй яратканымны беләсең ич.

– Шул күкәй дип гомер буе чистый җаныма төштең инде. Хәтереңә төшерәм: анысы йомырка дип атала. Син томанага бер үк нәрсәне аңлата-аңлата гарык булдым инде.

– Телеңә салынма, йәтрәк бул!

Бераздан фатирның тышкы ишеге шартлап ябылуы хуҗаның урамга чыгып китүен аңлата иде...

Илле ел элек туйга бүләк ителгән сәгатьнең күкесе көндезге уникене сукканда Харис абзый фатирына кайтып керде. Аның йөзенә алсу төс йөгергән, әмма сөйләгәндә теленең көрмәкләнүе сизелеп тора.

Шулай да, йомыркаларны кабул итеп алганда, Ыслания иренә рәхмәтле карашын кызганмады. Төенчекне чишеп җибәрүгә генә, корт чаккандай чырылдап, әче тавыш белән кычкырып җибәрде.

– Тагын вак күкәйләр алып кайткансың, исерекбаш...

– Син кушканча – күзлегемне киеп, узган атнада алган адәмнең йомыркаларын сайлаган идем югыйсә, – дип акланырга тырышты башына күкәй казасы төшкән ир.

– Ул көчле пыялалы күзлегең чыпчык күкәен дә тәва кошыныкы хәтле зурайтып күрсәтә бит. Ахмак, аның күкәе башкаларныкына караганда күпкә кечкенә икәнен син түгел, мин дә күптән беләм...


– Ярый әле кеше ишетмәде. Әллә ни уйлаулары бар, – диде дә Харис, тагын өстәргә чыгып китте.

Күпләребезнең хатыннары шундыйрак бит, җәмәгать, чамалап сөйләшә белмиләр.



БЕЗНЕҢ ВЕРНИСАЖ

Константин ВАСИЛЬЕВ



Быел Константин **ВАСИЛЬЕВның** туына – 75 ел. Сәнгать сөючеләргә ул славян-норман эпосына багышланган үзенчәлекле картиналары белән билгеле. Ә аның 60-70 нче елларда «Чаян» белән хезмәттәшлек итүе турында сирәк кеше генә беләдер. Бүгенге вернисаж укучыларыбызны фани дөньядан иртә киткән якташыбыз – талантлы рәссамның карикатуралары белән таныштыра.









– Авыр машина төзү институтын тәмамладым, ләкин машинаның җиңелрәген сайларга булдым...

